| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ГЛАВА АМЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘМЗӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | Яңа | **КАРАР** |
| «29» марта 2024 года | Әмзә ав. | № 2 |

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Чурабатыр авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 10 апрелендә 11 сәгать 30 минутка Чурабатыр авылы, Октябрь урамы, 9нчы йорт адресы буенча урнашкан йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Чурабатыр авылында яшәүче гражданнардан үзара салымын кертү, элек расланган карарларга үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлегенең Чурабатыр авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 15 ноябрендәге 1 номерлы карары;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлегенең Чурабатыр авылында гражданнар Җыенының 15.11.2023 ел, № 2 карары.

2. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

3.1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлегенең Чурабатыр авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карарның 1 пунктына үзгәрешләр кертергә ризамы, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, 15.11.2023 ел, № 1:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлегенең Чурабатыр авылында гражданнар җыены узган дип танырга гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

"Сез 2024 елда Әмзә авыл җирлегенең Чурабатыр авылы территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар тыш 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү ризамы?" дигән сорау буенча карарны танырга:

1) Чурабатыр авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (СШР-2.0 П тагылмалы җиһазларны сатып алу).

3.2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлегенең Чурабатыр торак пунктында гражданнар Җыенының 15.11.2023 ел, №2 карарына үзгәрешләр кертергә ризамы, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

1. 2024 елда Әмзә авыл җирлегенең Чурабатыр авылы территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар тыш 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә

1) Чурабатыр авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (СШР-2.0 П тагылмалы җиһазларны сатып алу).

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Чурабатыр авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Әмзә авыл җирлеге башлыгы Ә.Ф.Сафиуллина